## Файдалы киңәш

### Халык медицинасында тозны ничек кулланалар?

Тозны *«ак үлем»гә* тиңләүчеләр бар.

Ә халык медицинасында моңа ничек карыйлар соң?

Авыруларны дәвалауда халык үзе уйлап тапкан ысуллар белән кызыксынучы табибә Фәридә Александрова менә нәрсәләр ди:

«Им-томчылар, үлән белән эш итүчеләр тозны могҗизалы дәва чарасы, дип санылар.

Борынгы греклар ук инде ашаганнан соң тоз бөртеге суырырга киңәш иткәннәр. Бу тәкъдим шуңа нигезләнгән — тоз ашказаны согы бүленеп чыгуны тизләтә, ә бу сокта иске күзәнәкләрнең таркалуы өчен кирәкле элементлар бар».

Академик Б.Болотов үзенең озын гомерлелек турындагы тәгълиматына нигез итеп биш кагыйдәне алган.

Шуларның берсе - яшь күзәнәкләрнең артуы. Аш тозының ашказанында *пепсин ферментлары* бүлеп чыгару үзлеге бар.

Шуны күздә тотып, академик ашаганнан соң, ярты сәгать үткәч тә, авызга берничә бөртек аш тозы кабарга һәм берничә минуттан соң тозлы төкерекне йотып җибәрергә киңәш итә.

**Халык медицинасында тоз белән аллергия авыруларын дәвалыйлар.**

Тән тиресенә куе тоз эретмәсе сөртәсең һәм аны су белән юып төшермәскә кирәк.

Кипкән тоз үзе коелып бетәргә тиеш.

Битне чистарту өчен өстенә тоз сибелгән кыяр белән ышкыйлар. Тозлы терлек маен ышкырга да ярый, май биткә тиз сеңә, ә тозын су белән генә (сабынсыз) юып төшерәсең.

Башыңда тимрәү булса, көн дә тозлы суда чылатылган юеш башлык кияргә кирәк.

Менә шундый гади генә киңәшләр.

* * *

---

## Татар телен өйрәнәбез

### Безнең сүзлек

**Кургаш** - олово, свинец

**Зәңге** - цынга

**Түштамга** - нагрудный знак

**Садә** - простой, несложный, скромный, обыкновенный

**Тәкълид** - ияру

**Гыйбрани теле** - иврит

**Гозерсез** - сәбәпсез

**Пляж** - комлык

**Мостәхәб** - саваплы

**Теһеран** - Тегеран

**Гомум ятак** - общежитие

**Сәетләр** - Пәйгамбәребезнең (с.г.в.) нәселеннән килгән кешеләр

**Һолландия** - Голландия

**Алмания** - Германия

**Тимерхут** - тарантас

## Матур әйберләрне саклыйлар

# Зиннәт урыннарын ачмагыз

Дөньяда булган хәлләрне көн саен күрсәтәләр. Шуларның кайберәүләре безгә Коръән аятьләрен искә төшерер.

Чынлап та, кайбер аятьләрне дуслар хәтерләтер, ә кайберәүләрен - дошманнар.

Беләсез, соңгы вакытларда мәгълүмат чараларында мөселман хатыннарының киемнәренә күп игътибар бирелә башлады.

**Әмма ул яхшы яктан түгел, фәкать ул киемне тыю хакында**.

Бик күп илләрдә мөселман хатыннарының киемен тыю тарала башлады.

Әйе, бу - Аллаһының имтиханы.

Фәкать сорау бирәсе килә.

Без, мөселманнар, нинди гөнаһ эшләдек соң?

Әмма нигә бүген мөселманнарга тиләләрнең күлмәген кидертмәкче булалар?

Вә бу кешеләр нигә икән үз көчләрен кирәкмәгән әйберләргә сарыф итәләр?

Бу кешеләр нигә тагын да мөһим булган мәсьәләләрне оныталар да, кирәкмәгәннәре белән вакытларын әрәм итәләр?

Яулыкларны тыю да шуларның берсе булып тора.

Вә бүген Көнбатыш дөньясы мөселман хатын-кызының капланып йөрүенә каршы бер сугыш ачкан кебек һәм бу сугыш үткән гасырның башында башланды.

**Беренче Бөтендөнья сугышына кадәр мөселман илләрендә генә түгел, ә христиан дөньясында да хатыннар башларын каплап йөргәннәр.**

Аны Беренче Бөтендөнья сугышында төшерелгән фоторәсемнәрдән күрә аласыз. Шуны әйтәсе килә. Яулык мөселман киеме элементы түгел, ә бөтендөнья кешеләренең киенү рәвеше. Адәм үзенең кеше икәнен күргәч, өстен яба башлаган. Моны безгә Коръән әйтә. Чөнки кешегә рух өрелеп, иман кергәч, кеше булуның иң беренче шарты оялу булды.

Пәйгамбәребез (с.г.в.) бер хәдисендә шулай дип әйтә:

**«Әгәр синдә оят юк икән, теләгәнеңне эшли алырсың».**

Бүтән җанлылар белән кешене аерган нәрсә шул - оялу. Шуңа күрә без киемгә ихтыяҗ күрәбез.

**Әмма хайваннар киемдә ихтыяҗ күрмәс, чөнки оялмас.**

Коръән мөселманнарга *“киенүне”* түгел, ә *“каплануны”* әмер итә. Шуңа күрә *“мөселман”* киеме, дип әйтү ялгыш. *“Мөселманча каплану”,* дию дөрес.

Нигә икән?

Бу сорауның җавабын Коръәннең «Нур» сүрәсенең 30, 31аятьләрендә таба алабыз:

**«Әйт бу мөэмин ирләргә, күз карашларын кыссыннар һәм эчендә җенси булган карашлардан ваз кичсеннәр.**

**һәм җенси әгъзаларын гөнаһ эшләүдән сакласыннар».**

Ягъни ирләргә әйт, хатын - ир мөгамәләсен бозмас өчен берберләренә кыек карамасыннар, карашларын, күзләрен пычратмасыннар һәм караганнарын да пычратмасыннар. Бу - иң чиста булганы.

**Күзеңне пычратсаң, күңелең пычраныр,**
**күңелеңне пычратсаң, акылың, калебең,**
**иманың пычраныр**
**һәм үзең пычранырсың.**

Әмма Аллаһы синең чиста булуыңны теләр. Ягъни хатын - ир элемтәсе бозылмасын, шәригатьнең чикләре эчендә дәвам итсен өчен. Шуңа күрә Аллаһы башта ирләргә күз карашыгыз чиста булсын, дип әмер итә. Без бу аятьтән шуны күрәбез. Ирләрнең күз карашы чиста булсын өчен мохитләрендә хатын-кызларның булуы кирәк.

Ягъни хатыннар булмаган бер урында бу аятьнең ни кирәге бар?

Исламда хатынсыз җәмгыять юк. Ислам шундый җәмгыятьләрне кабул итми.

**Хатын булачак, әмма син күзләреңне тәрбия итәчәксең.**

Шуңа мәчетләрдән хатыннарны кумаска кирәк. Чөнки алар да Ислам җәмгыятендә урын алырга тиеш. Кайбер ирләр тырышалар бүген мәчетләрдән хатын-кызларны ерагайтырга. Хатын-кыз фетнә дип.

Чынлап та, кайбер Ислам классик китапларында шулай язылa. Шуны ишеткәч, шулай әйтәсе килә:

**«Ий, ир кардәш, фетнә синең күзең күргән хатыннарда түгел, синең үзеңдә.**

**Күзләреңә хуҗа бул.**

**Бөтен нәрсә күзләрдән башлана.**

Коръәнебез әйтми сукыр булыгыз дип, хәтта карамагыз, дип тә әйтми, күз карашларыгызны кысыгыз, дип әйтә, чиста карагыз һәм кайбер күз карашларыннан ваз кичегез. Монда без Коръәннең ни кадәр кешелекле һәм ни кадәр тормышчан икәнлегенә хәйран калабыз. «Нур» сүрәсенең 31нче аятендә Аллаһы Тәгалә әйтә:

**«Әйт хатыннарга,**
**алар да күз карашларын кыссыннар,**
**кирәкмәгәннәреннән ваз кичсеннәр,**
**җенси әгъзаларын гөнаһтан сакласыннар**
**һәм кул белән йөзләреннән башка булган зиннәт урыннарын ачмасыннар».**

Кайбер ирләр әйтә: «Мин үземнән куркам, әгәр янымда хатын-кыз булса».

Ул кешегә без шулай җавап бирик. Ул хатын-кызның гаебе нидә?

Синең күзең начар икән, син аны тәрбия итәргә тиешсең.

Җәмгыятьтәге тормыш ирләр аерым, хатыннар аерым булсын, дип түгел, ә бергә булсыннар өчен.

Фәкать контрольдә тотсыннар.

**Ягъни Аллаһы сиңа күз биргән икән, аның белән бергә күз кабагын да биргән.**

**Акыл да биргән аның белән бергә.**

Әмма шуның белән бергә хатын-кызлар үз матурлыкларын, зиннәтләрен җәмгыятькә ачмасыннар.

**Аллаһы Тәгалә Үз җәмал (матур, күркәм) сыйфатларын хатыннарда күрсәтте.**

**Сез беләсез, әгәр бер матур әйбер булса, аның карaклары да күп булыр.**

**Шуңа күрә матур әйберләрне саклыйлар.**

Хатыннарны да җәмгыятьтән Аллаһы саклый, матурлыкларыгызны җәмгыятькә ачмагыз, дип кисәтеп. Чөнки ул җәмгыятьнең малы түгел.

Матурлыгыгызны кемгә күрсәтергә ярый икәнлеген Коръәндә әйтелә.

Нигә Аллаһы аны шулай кушты, дип сорасагыз, социаль тормышта ирләр белән хатыннар бергә торсын өчен.

Хатын кеше хатынлыгы белән түгел, кешелеге белән танылсын. Ягъни яулык ябынган хатын-кыз шуны әйтмәкче була: «Әй, ирләр, минем белән аралашасыгыз килә икән, хатынлыгым белән түгел, ә кешелегем белән элемтә ясаячаксыз».

Әмма шуны да әйтәсе килә.

Кайбер капланып йөргән хатыннарның йөрәкләре яулыклы түгел.

**Ә кайбер капланмаган хатыннарның йөрәкләре капланган.**

Без беләбез. Коръәннең бөтен максаты башта кешенең эчке дөньясын тәрбияләүдә.

Һәм Аллаһы Тәгалә Коръәндә әйтә:

**«Эчке киемегез иң хәерлеседер».**

Әфәнделәр, эчке дөньясы һәм тышкы дөньясы капланган хатыннарда ни кимчелек күрәсез?

Нигә аларның киемнәренә бәйләнәсез?

**Сөләйман хәзрәт ФӘХРИЕВ.**

**ВНИМАНИЕ НАЛОГОПЛАТЕЛЬЩИКОВ !!!**

ИФНС России по Промышленному району г. Самары сообщает:

Получать методологические разъяснения ФНС России теперь можно и по электронной почте!

Теперь пользователи сайта ФНС России могут по электронной почте получать сообщения о новых методологических разъяснениях, содержащихся в разделе сервиса «Разъяснения Федеральной налоговой службы, обязательные для применения налоговыми органами».

Для того, чтобы подписаться на рассылку новых методологических разъяснений, необходимо зарегистрироваться непосредственно в разделе «Разъяснения Федеральной налоговой службы, обязательные для применения налоговыми органами».

Также зарегистрироваться можно, обратившись к сервису «Почтовая рассылка сайта ФНС России» в разделе «Электронные услуги».

С помощью сервиса, который содержит разъяснительные письма по применению законодательства Российской Федерации о налогах и сборах, налогоплательщики могут узнавать о правилах применения тех или иных налоговых норм.

Все размещенные документы в разделе «Разъяснения Федеральной налоговой службы, обязательные для применения налоговыми органами» содержат правовую позицию, согласованную с Минфином России. Если налогоплательщики по тем или иным причинам не согласны с действиями налоговых органов на местах, они могут самостоятельно изучить разъяснения Службы и, в случае несоблюдения территориальными налоговыми органами принятых норм, сообщить об этом с помощью сервиса.

База данных сервиса еженедельно пополняется актуальными разъяснениями по вопросам методологии исчисления и уплаты всех налогов и сборов, имеющихся в налоговом законодательстве.

---

**ИФНС России по Промышленному району г. Самары сообщает:**

**Уважаемый налогоплательщик!**

На основании п. 2 ст. 88 Налогового кодекса Российской Федерации налоговая декларация по налогу на доходы физических лиц (форма 3-НДФЛ) подлежит камеральной налоговой проверке, срок проведения которой не может превышать трех месяцев со дня ее представления.

Информация о ходе проведения проверки представленной Вами налоговой декларации доступна на официальном сайте ФНС России www.nalog.ru в интерактивном сервисе «Личный кабинет налогоплательщика для физического лица».

Кроме того, с помощью сервиса «Личный кабинет налогоплательщика для физического лица» Вы сможете получать актуальную информацию о суммах начисленных и уплаченных налоговых платежей, о наличии переплат и задолженностей по налогам, об объектах движимого и недвижимого имущества; контролировать состояние расчетов с бюджетом; получать и распечатывать налоговые уведомления и квитанции на уплату налоговых платежей (до наступления срока уплаты); оплачивать налоговую задолженность и налоговые платежи, а также обращаться в налоговые органы без личного визита.

Поскольку сервис «Личный кабинет налогоплательщика для физического лица» содержит данные, составляющие налоговую тайну, в целях Вашей безопасности для подключения к сервису необходимо получить реквизиты доступа (пароль и логин).